РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**КАРАР**

**2019 елның 26 ноябре** **54 номерлы**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Атабай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **КАРАР** бирәм:

1. 2019 елның 8 декабрендә сәгать 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Атабай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Атабай авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу һәм Яңа елга бизәү әйберләре сатып алу;
- зират коймасын карап тоту һәм ремонтлау, триммер һәм бензин пычкысы сатып алу;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру.

"ӘЙЕ" "ЮК"

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы И. Х. Сәгъдиев